1. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы (алга таба – Иҗтимагый палата) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә аерым гавами вәкаләтләрне башкаручы башка оешмалар эшчәнлегенә иҗтимагый контрольне гамәлгә ашыру максатларында дәүләт сәясәтен булдырганда һәм гамәлгә ашырганда гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, коммерциягә карамаган оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының (алга таба – гражданнар) һәм һөнәри, социаль төркемнәрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен белдерү һәм яклау өчен булдырылган, эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларның (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлеген тәэмин итә.

2. Иҗтимагый палата аның эшчәнлегендә гражданнарның һәм коммерциягә карамаган оешмаларның ихтыярый катнашуы нигезендә төзелә.

3. “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” исеме Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары исемнәрендә, шулай ук оешмалар исемнәрендә кулланыла алмый.

4. Иҗтимагый палата юридик зат түгел.

5. Иҗтимагый палатаның урнашкан җире – Казан шәһәре.

2 статья. **Иҗтимагый палатаның максатлары һәм бурычлары**

Иҗтимагый палата Татарстан Республикасын икътисадый һәм социаль үстерүнең иң әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итү, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау, демократия институтларын үстерү өчен гражданнарның, коммерциягә карамаган оешмаларның, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының иҗтимагый әһәмияткә ия мәнфәгатьләрен килештерүне түбәндәге юллар белән тәэмин итәргә бурычлы:

1) дәүләт сәясәтен булдыруга гражданнарны һәм коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итү, аларның дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлеген тәэмин итү;

2) гражданнарның конституциячел хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, коммерциягә карамаган оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән граждан инициативаларын чыгару һәм хуплау;

3) эшчәнлекләре Татарстан Республикасында граждан җәмгыятен үстерүгә юнәлдерелгән коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт ярдәмен күрсәтү өлкәсендә өстенлекләрне билгеләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тәкъдимнәр әзерләү;

4) Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Россия Федерациясе субъектларының иҗтимагый палаталары, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең иҗтимагый советлары (алга таба – муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый советлары), Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы иҗтимагый советлар белән үзара эшләү;

5) муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый советларына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы иҗтимагый советларга, эшчәнлекләре Татарстан Республикасында граждан җәмгыятен үстерүгә юнәлдерелгән коммерциягә карамаган оешмаларга мәгълүмати, методик һәм башка ярдәм күрсәтү;

6) социаль-икътисадый өлкәне үстерү проблемалары буенча Татарстан Республикасы законнарын, республика программаларын, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын гамәлгә ашыру барышына иҗтимагый мониторинг үткәрү һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, программаларны башкару механизмына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тәкъдимнәр әзерләү.

3 статья. **Иҗтимагый палата эшчәнлегенең хокукый нигезе**

Иҗтимагый палата үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, “Россия Федерациясе субъектлары иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында” 2016 елның 23 июнендәге 183-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив

хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

4 статья. **Иҗтимагый палата төзүнең һәм аның эшчәнлегенең принциплары**

Иҗтимагый палата түбәндәге принциплар нигезендә төзелә һәм үз эшчәнлеген башкара:

1) кешенең һәм гражданның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өстенлеге;

2) законлылык;

3) граждан җәмгыяте институтларының хокуклары тигезлеге;

4) үзидарә;

5) бәйсезлек;

6) ачыклык һәм хәбәрдарлык.

5 статья. **Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының этика кодексы**

Иҗтимагый палата советы Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының этика кодексын (алга таба – Этика кодексы) әзерли һәм аны Иҗтимагый палата тарафыннан раслауга тәкъдим итә. Иҗтимагый палата әгъзалары Этика кодексында каралган таләпләрне һичшиксез үтәргә тиеш.

2 бүлек. **Иҗтимагый палата төзүнең тәртибе**

6 статья. **Иҗтимагый палата составы**

1. Иҗтимагый палата 60 кеше составында төзелә.

2. Иҗтимагый палата составының өчтән бере (20 кеше) гомумроссия һәм регионара иҗтимагый берләшмәләрнең Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән структур бүлекчәләренең тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

3. Иҗтимагый палата составының өчтән бере (20 кеше) Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән коммерциягә карамаган оешмаларның, шул исәптән региональ иҗтимагый берләшмәләрнең тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (алга таба – Дәүләт Советы) тарафыннан раслана.

4. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан расланган Иҗтимагый палата әгъзалары һәм Дәүләт Советы раслаган Иҗтимагый палата әгъзалары Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләр тәкъдим иткән кандидатуралар арасыннан Иҗтимагый палата әгъзалары составының калган өчтән берен (20 кеше) билгелиләр.

5. Иҗтимагый палатаның яңа раслана торган составына кадәр рәттән ике составта Иҗтимагый палата әгъзалары булган затлар яңа составтагы Иҗтимагый палата әгъзалары була алмыйлар.

7 статья. **Иҗтимагый палата әгъзаларына кандидатлар күрсәтү тәртибе**

1. Иҗтимагый палата әгъзаларына кандидатлар күрсәтү хокукына коммерциягә карамаган оешмалар ия.

2. “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында” 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзаларына кандидатлар күрсәтә алмый торган коммерциягә карамаган оешмаларга Иҗтимагый палата әгъзаларына кандидатлар күрсәтү рөхсәт ителми.

3. Һөнәри һәм социаль төркемнәрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен белдерү һәм яклау өлкәсендә кимендә өч ел эшләгән һәр оешма Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны булган гражданнар арасыннан бер кандидат тәкъдим итәргә хокуклы.

4. Иҗтимагый палатага үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән оешма Иҗтимагый палатаның яңа составы төзелү турында мәгълүмати хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә тиешенчә Татарстан Республикасы Президентына, Дәүләт Советына яисә гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палатага – аның яңа составына үз вәкилен кертү турында закон көченә яисә шушы оешманың уставы нигезендә тиешле вәкаләтләргә ия оешманың җитәкче коллегиаль органы карары белән рәсмиләштерелгән гариза, ә коллегиаль орган булмаганда закон көченә яисә шушы оешманың уставы нигезендә бу оешма исеменнән эшләү хокукына ия башка органның карары буенча гариза җибәрә. Гаризага оешманы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның күчермәсе, оешма уставының күчермәсе һәм Иҗтимагый палата әгъзаларына кандидат күрсәтү хакында карар кабул иткән органның вәкаләтләрен раслый торган башка документлар, оешма уставы нигезендә вәкаләтле булган органның Иҗтимагый палата әгъзаларына кандидат күрсәтү турындагы карары, кандидат хакында белешмәләр һәм кандидатның Иҗтимагый палата эшендә катнашуга язма ризалыгы, оешма эшчәнлеге турында мәгълүмат теркәп бирелә.

5. Иҗтимагый палата әгъзаларының вәкаләтләр чоры тәмамланырга кимендә өч ай кала Дәүләт Советы рәсми рәвештә массакүләм мәгълүмат чараларында Иҗтимагый палатаның яңа составын төзүнең әлеге Закон белән билгеләнгән процедурасын башлау турында мәгълүмати хәбәр бастырып чыгара, шулай ук аны үзенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

8 статья. **Иҗтимагый палата составын раслау**

1. Татарстан Республикасы Президенты һәм Дәүләт Советы Иҗтимагый палата составына оешмалар вәкилләрен кертү турында гаризалар кабул итү

туктатылган көннән алып бер ай эчендә Иҗтимагый палата әгъзаларын раслыйлар.

2. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кандидатураларны карау һәм Иҗтимагый палата әгъзаларын раслау тәртибен Татарстан Республикасы Президенты билгели.

3. Дәүләт Советы тарафыннан кандидатураларны карау һәм Иҗтимагый палата әгъзаларын раслау тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Президенты раслаган Иҗтимагый палата әгъзалары һәм Дәүләт Советы раслаган Иҗтимагый палата әгъзалары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләр тәкъдим иткән кандидатуралар арасыннан Иҗтимагый палата әгъзалары составының өчтән берен билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Регламенты (алга таба – Иҗтимагый палата Регламенты) белән билгеләнә.

5. Иҗтимагый палатаның яңа составын төзегәндә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана торган Иҗтимагый палата әгъзаларының исемлекләрендә, Дәүләт Советы тарафыннан раслана торган Иҗтимагый палата әгъзалары исемлекләрендә, Татарстан Республикасы Президенты һәм Дәүләт Советы раслаган Иҗтимагый палата әгъзалары тарафыннан раслана торган Иҗтимагый палата әгъзалары исемлекләрендә элекке составның кимендә яртысы үзгәртелергә тиеш.

6. Иҗтимагый палата әгъзаларының расланган исемлекләре бер атна эчендә рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

7. Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Иҗтимагый палатаның киткән әгъзасы урынына яңасын раслау вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Иҗтимагый палата әгъзасын раслаган орган яисә Татарстан Республикасы Президенты һәм Дәүләт Советы тарафыннан расланган Иҗтимагый палата әгъзалары тарафыннан әлеге Законның шушы статьясында һәм 14 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда башкарыла.

8. Иҗтимагый палата составына вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Иҗтимагый палата әгъзасы урынына вәкил күрсәткәндә, Иҗтимагый палатага үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән оешма Иҗтимагый палата әгъзаларына кандидатлар күрсәтү турында мәгълүмати хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә – вәкаләтләре туктатылган Иҗтимагый палата әгъзасын раслаган органга, ә әлеге Законның 6 статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләп куелган Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләре туктатылганда Иҗтимагый палатага аның составына үз вәкилен кертү хакында гариза җибәрә.

9 статья. **Иҗтимагый палатаның беренче утырышы**

1. Иҗтимагый палата, әгәр аның составына Иҗтимагый палата әгъзаларының әлеге Законда билгеләнгән санының дүрттән өченнән артыгы керсә, хокуклы була.

2. Хокукка ия составта төзелгән Иҗтимагый палатаның беренче утырышы гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палата әгъзаларының вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән алып ун көннән дә соңга калмыйча үткәрелергә тиеш.

3. Иҗтимагый палатаның беренче утырышын үткәрергә әзерлекне оештыруны – элеккеге составтагы Иҗтимагый палата советы, ә Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта Татарстан Республикасы Президенты вәкаләт биргән орган гамәлгә ашыра.

4. Яңа составтагы Иҗтимагый палатаның беренче утырышы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан чакырыла һәм аны Иҗтимагый палатаның яшь буенча иң өлкән әгъзасы ача.

10 статья. **Иҗтимагый палатаның вәкаләтләр чоры**

1. Иҗтимагый палата әгъзаларының вәкаләтләр чоры өч ел, һәм ул яңа составтагы Иҗтимагый палатаның беренче утырышы көненнән санала. Яңа составтагы Иҗтимагый палатаның беренче утырышы көненнән алып гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палата әгъзаларының вәкаләтләре туктатыла.

2. Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре, Иҗтимагый палата аның әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән беренең яисә Иҗтимагый палата советының инициативасы белән үз-үзен таркату турында карар кабул иткән очракта, Иҗтимагый палата Регламентында билгеләнә торган тәртиптә вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.

3. Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Дәүләт Советы вәкаләтләр вакытыннан алда туктатылган көннән алып җиде көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә массакүләм мәгълүмат чараларында Иҗтимагый палатаның яңа составын төзү турында мәгълүмати хәбәр бастырып чыгара, шулай ук аны үзенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

3 бүлек. **Иҗтимагый палата әгъзасы**

11 статья. **Иҗтимагый палата әгъзасы**

1. Унсигез яшенә җиткән Россия Федерациясе гражданы Иҗтимагый палата әгъзасы була ала.

2. Түбәндәгеләр Иҗтимагый палата әгъзалары була алмый:

1) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзалары, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте әгъзалары, судьялар, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүче башка затлар, Татарстан Республикасы Президенты, Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче башка затлар, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары, муниципаль вазыйфаларны биләүче башка затлар,

федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар;

2) суд карары нигезендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

3) юкка чыгарылмаган яисә кире алынмаган хөкем ителүе булган затлар;

4) башка дәүләт (башка дәүләтләр) гражданлыгы, яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булган затлар;

5) элегрәк әлеге Законның 14 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты нигезендә Иҗтимагый палата әгъзасы булуы туктатылган затлар. Бу очракта Иҗтимагый палата әгъзасы булуны тыю Иҗтимагый палатаның киләсе составы эшенә генә кагыла.

3. Иҗтимагый палата әгъзалары үз эшчәнлекләрен иҗтимагый башлангычларда башкара.

4. Иҗтимагый палата әгъзасының сәяси партия әгъзасы булуы аның вәкаләтләр чорына туктатылып тора.

5. Иҗтимагый палата әгъзаларының милли, дини, региональ принцип буенча яисә нинди партиядә торуларына бәйле рәвештә берләшүе рөхсәт ителми.

6. Иҗтимагый палата әгъзалары үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда коммерциягә карамаган оешмаларның карарларына бәйле түгел.

7. Иҗтимагый палата әгъзасын кире чакыртып алу рөхсәт ителми.

12 статья. **Иҗтимагый палата әгъзаларының аның эшендә катнашуы**

1. Иҗтимагый палата әгъзасы Иҗтимагый палата утырышларында шәхсән катнашырга тиеш. Тавыш бирү хокукын башка затка тапшыру рөхсәт ителми.

2. Иҗтимагый палата әгъзасы Иҗтимагый палатаның кимендә бер комиссиясендә эшләргә тиеш.

3. Иҗтимагый палата әгъзасы Иҗтимагый палата, Иҗтимагый палата советы, Иҗтимагый палата комиссияләре һәм Иҗтимагый палатаның эшче төркемнәре эшчәнлегенең теләсә кайсы мәсьәләсе буенча үз фикерен ирекле әйтергә хокуклы.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары Иҗтимагый палата әгъзаларына Федераль законда, әлеге Законда, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында, Иҗтимагый палата Регламентында билгеләнгән вәкаләтләрен башкаруда ярдәм итәргә тиеш.

13 статья. **Иҗтимагый палата әгъзасының таныклыгы**

1. Иҗтимагый палата әгъзасы аның вәкаләтләрен раслаучы документ булган Иҗтимагый палата әгъзасы таныклыгына ия була.

2. Иҗтимагый палата әгъзасы таныклыгының үрнәге һәм тасвирламасы Иҗтимагый палата тарафыннан раслана.

14 статья. **Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләрен туктату һәм туктатып тору**

1. Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләре Иҗтимагый палата Регламентында каралган тәртиптә түбәндәге очракларда туктатыла:

1) аның вәкаләтләр чоры тәмамланса;

2) аның тарафыннан Иҗтимагый палата составыннан чыгу турында гариза бирелсә;

3) сәламәтлеге торышы буенча озак вакыт дәвамында Иҗтимагый палата эшендә катнашырга сәләтсез булса;

4) Этика кодексын тупас рәвештә бозса – Иҗтимагый палата утырышында Иҗтимагый палата әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә;

5) Иҗтимагый палата әгъзасы вафат булса;

6) Иҗтимагый палата Регламенты нигезендә Иҗтимагый палата утырышларында, аның органнары эшендә мөһим сәбәпләрсез системалы рәвештә катнашмаса;

7) әлеге Законның 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Иҗтимагый палата әгъзасы статусына туры килми торган сәбәпләр ачыкланса;

8) Иҗтимагый палата әгъзасы Иҗтимагый палатаның беренче утырышы уздырылган көннән алып утыз көн үткәннән соң әлеге Законның 11 статьясындагы 4 өлешендә каралган таләпне үтәмәсә.

2. Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләре Иҗтимагый палата Регламентында каралган тәртиптә түбәндәге очракларда туктатылып тора:

1) Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә ул җинаять кылуда гаепләнсә;

2) аңа административ арест рәвешендә административ җәза билгеләнсә;

3) ул Россия Федерациясе Президенты вазыйфасына кандидат, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатына кандидат, Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат, Дәүләт Советы депутатына кандидат, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатына кандидат, башка муниципаль вазыйфа биләүгә кандидат, кандидатның (сайлау берләшмәсенең) ышанычлы заты яисә вәкаләтле вәкиле буларак теркәлсә.

3. Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләре шулай ук Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта да туктатыла.

4. Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләре әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 (Иҗтимагый палата әгъзасы аны әлеге Законның 11 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларга сайлауга яисә билгеләп куюга бәйле рәвештә гариза биргән очракта), 3, 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча вакытыннан алда туктатылганда, аның кандидатурасын күрсәткән оешма, шушы әгъзаның вәкаләтләре туктатылган көннән алып җиде көн эчендә шушы оешмадан – Иҗтимагый палата әгъзасын раслаган органга, ә әлеге Законның 6 статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләп куелган Иҗтимагый палата

әгъзасының вәкаләтләре туктатылганда Иҗтимагый палатага яңа кандидатура буенча тәкъдим кертә ала.

5. Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләре әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән нигезләр буенча вакытыннан алда туктатылган очракта, вәкаләтләр вакытыннан алда туктатылган көннән алып җиде көннән дә соңга калмыйча йә әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә оешма тарафыннан яңа кандидатура күрсәтә алу срогы тәмамлангач, Иҗтимагый палата советы массакүләм мәгълүмат чараларында Иҗтимагый палата әгъзаларына кандидатлар күрсәтү турында мәгълүмати хәбәр бастырып чыгара.

4 бүлек. **Иҗтимагый палата эшчәнлеген оештыру һәм аның структурасы**

15 статья. **Иҗтимагый палата Регламенты**

1. Иҗтимагый палата Иҗтимагый палатаның Регламентын раслый.

2. Иҗтимагый палата Регламентында түбәндәгеләр билгеләнә:

1) Иҗтимагый палата әгъзаларының аның эшчәнлегендә катнашу тәртибе;

2) Иҗтимагый палата утырышларын, Иҗтимагый палатаның комиссияләре һәм эшче төркемнәре утырышларын, җәмәгать тыңлауларын уздыру сроклары һәм тәртибе;

3) Иҗтимагый палата советының составы, вәкаләтләре һәм аның эшчәнлек тәртибе;

4) Иҗтимагый палата рәисен сайлау һәм аны вазыйфасыннан азат итү тәртибе, аның вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе;

5) Иҗтимагый палата рәисе урынбасарларын сайлау һәм аларны вазыйфаларыннан азат итү тәртибе, аларның вәкаләтләре, саны һәм эшчәнлек тәртибе;

6) Иҗтимагый палатаның комиссияләрен, эшче төркемнәрен төзү һәм аларның эшчәнлек тәртибе, шулай ук аларның җитәкчеләрен сайлау тәртибе һәм аларның вәкаләтләре;

7) Федераль закон һәм әлеге Закон нигезендә Иҗтимагый палата әгъзаларының эшчәнлеген туктату һәм туктатып тору тәртибе;

8) әлеге Законның 6 статьясындагы 4 өлеше нигезендә яңа составтагы Иҗтимагый палата әгъзаларын раслау тәртибе;

9) Иҗтимагый палата, Иҗтимагый палата советы, Иҗтимагый палата комиссияләре һәм эшче төркемнәре карарлары рәвешләре һәм аларны кабул итү тәртибе;

10) Иҗтимагый палата аппаратының эшчәнлек тәртибе;

11) Иҗтимагый палата эшенә гражданнарны, шулай ук аның составына вәкилләре кермәгән коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итү тәртибе һәм аларның Иҗтимагый палата белән үзара эшләү рәвешләре;

12) Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында Иҗтимагый палатаның еллык докладын әзерләү һәм бастырып чыгару тәртибе;

13) мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларында федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасында төзелгән җәмәгать күзәтчелеге комиссиясе белән Иҗтимагый палата органнарының үзара эшләү тәртибе;

14) федераль законнар нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы составына үз составыннан вәкил сайлау тәртибе;

15) Иҗтимагый палатаны эчке оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе буенча башка мәсьәләләр.

3. Иҗтимагый палата Регламентына үзгәрешләр Иҗтимагый палата советы тәкъдиме яисә Иҗтимагый палата әгъзаларының кимендә өчтән беренең инициативасы буенча Иҗтимагый палатаның карары белән раслана.

16 статья. **Иҗтимагый палата эшенең төп рәвешләре**

1. Иҗтимагый палата эшенең төп рәвешләре булып Иҗтимагый палата утырышлары, Иҗтимагый палата советы утырышлары, Иҗтимагый палатаның комиссияләре һәм эшче төркемнәре утырышлары, җәмәгать тыңлаулары тора.

2. Иҗтимагый палата утырышлары Иҗтимагый палатаның эш планы нигезендә, әмма кимендә дүрт айга бер мәртәбә үткәрелә.

3. Иҗтимагый палата утырышында Иҗтимагый палата әгъзаларының билгеләнгән санынннан яртысыннан күбрәге катнашса, ул тулы хокуклы булып санала.

4. Иҗтимагый палата утырышларын Иҗтимагый палата советы чакыра.

5. Иҗтимагый палата утырышында Иҗтимагый палата советының үз инициативасы яисә Татарстан Республикасы Президенты, Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – Министрлар Кабинеты) тәкъдимнәре буенча кертелә торган мәсьәләләр карала, шулай ук Иҗтимагый палата Регламентында билгеләнә торган тәртиптә Иҗтимагый палата әгъзалары тарафыннан тәкъдим ителә торган мәсьәләләр каралырга мөмкин.

6. Иҗтимагый палатаның бары тик үзенең компетенциясенә түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү керә:

1) Иҗтимагый палата Регламентын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү;

2) Иҗтимагый палата рәисен һәм Иҗтимагый палата рәисе урынбасарларын сайлау;

3) Иҗтимагый палата комиссияләре һәм эшче төркемнәре санын, исемнәрен раслау һәм эшчәнлекләренең юнәлешен билгеләү;

4) Иҗтимагый палата комиссияләре рәисләрен һәм аларның урынбасарларын сайлау.

7. Эшләү чорында Иҗтимагый палата Иҗтимагый палата компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне карарга һәм алар буенча карарлар кабул итәргә хокуклы.

8. Әлеге статьяның 6 өлешендәге 2 – 4 пунктларында күрсәтелгән мәсьәләләр тулы хокуклы составта оешкан Иҗтимагый палатаның беренче утырышында каралырга тиеш.

9. Иҗтимагый палатаның чираттан тыш утырышы Иҗтимагый палата рәисе, Иҗтимагый палата советы яисә Иҗтимагый палата әгъзаларының кимендә өчтән бере инициативасы белән чакырылырга мөмкин.

17 статья. **Иҗтимагый палата органнары**

Иҗтимагый палата органнары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Иҗтимагый палата советы;
2) Иҗтимагый палата рәисе;
3) Иҗтимагый палата комиссияләре.

18 статья. **Иҗтимагый палата советы**

1. Иҗтимагый палата утырышлары арасындагы чорда Иҗтимагый палатаның эшче органын Иҗтимагый палатаның беренче утырышында Иҗтимагый палата вәкаләтләренең бөтен чорына сайлана торган Иҗтимагый палата советы тәшкил итә.

2. Иҗтимагый палата советының санлы составы һәм аны төзү тәртибе Иҗтимагый палата утырышында билгеләнә.

3. Иҗтимагый палата советына Иҗтимагый палата рәисе, Иҗтимагый палата рәисе урынбасарлары, Иҗтимагый палата комиссияләре рәисләре, Иҗтимагый палатаның Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы составында вәкил булып торучы әгъзасы, Иҗтимагый палата аппараты җитәкчесе керә. Иҗтимагый палата советы даими эшләүче орган булып тора.

4. Иҗтимагый палата советы:

1) Иҗтимагый палатаның еллык эш планын раслый һәм аңа үзгәрешләр кертә;

2) Иҗтимагый палатаның чираттан тыш утырышын уздыру турында карар кабул итә;

3) Иҗтимагый палата утырышын үткәрү датасын билгели һәм көн тәртибенең проектын раслый;

4) Иҗтимагый палата аппараты җитәкчесе вазыйфасына кандидатура буенча тәкъдим кертә;

5) Иҗтимагый палата эшенә гражданнарны һәм вәкилләре Иҗтимагый палата составына кермәгән коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итү турында карар кабул итә;

6) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт оешмаларына һәм муниципаль оешмаларга, федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә аерым гавами вәкаләтләрне башкаручы бүтән оешмаларга Иҗтимагый палата гарызнамәләрен җибәрә;

7) Этика кодексын эшли һәм Иҗтимагый палата раславына кертә;

8) Иҗтимагый палата рәисенә, Иҗтимагый палата комиссияләренә, Иҗтимагый палата комиссияләре рәисләренә, Иҗтимагый палата эшче төркемнәре җитәкчеләренә йөкләмәләр бирә;

9) Иҗтимагый палата Регламентын үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

10) Татарстан Республикасы законнары һәм Иҗтимагый палата Регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

19 статья. **Иҗтимагый палата рәисе, аның урынбасарлары**

1. Иҗтимагый палата рәисе Иҗтимагый палата әгъзалары арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән сайланып куела.

2. Иҗтимагый палата рәисе:

1) Иҗтимагый палата советын җитәкли һәм аның эшен оештыра;

2) Иҗтимагый палата, Иҗтимагый палата советы, Иҗтимагый палата комиссияләре һәм эшче төркемнәре эшчәнлеген оештыруны гамәлгә ашыра;

3) Иҗтимагый палата һәм Иҗтимагый палата советы утырышларында рәислек итә;

4) Иҗтимагый палата советы белән килештереп, Иҗтимагый палата рәисе урынбасарларының бурычларын билгели;

5) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, коммерциягә карамаган оешмалар, башка органнар һәм оешмалар, гражданнар белән мөнәсәбәтләрдә Иҗтимагый палата вәкиле була;

6) Иҗтимагый палата советының чираттан тыш утырышын үткәрү турында тәкъдим белән чыга;

7) Иҗтимагый палата аппараты эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

8) Иҗтимагый палата, Иҗтимагый палата советы кабул иткән карарларны, мөрәҗәгатьләрне һәм башка документларны, шулай ук Иҗтимагый палата гарызнамәләрен имзалый;

9) Иҗтимагый палата Регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3. Иҗтимагый палата рәисе Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы составына сайланган очракта, ул Иҗтимагый палата рәисе вәкаләтләрен үз өстеннән төшерергә тиеш.

4. Иҗтимагый палата рәисе урынбасарлары Иҗтимагый палата рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый палата утырышында Иҗтимагый палата әгъзалары арасыннан сайланып куела һәм вазыйфаларыннан азат ителә.

20 статья. **Иҗтимагый палата комиссияләре һәм эшче төркемнәре**

1. Әлеге Закон белән Иҗтимагый палата карамагына кертелгән мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен аның эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча комиссияләр һәм эшче төркемнәр төзелә.

2. Иҗтимагый палата комиссияләре составына Иҗтимагый палата әгъзалары керә.

3. Иҗтимагый палатаның эшче төркемнәре составына Иҗтимагый палата әгъзалары, коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре, башка гражданнар керергә мөмкин.

21 статья. **Иҗтимагый палата, Иҗтимагый палата советы, Иҗтимагый палата комиссияләре һәм эшче төркемнәре карарлары**

1. Иҗтимагый палата, Иҗтимагый палата советы, Иҗтимагый палата комиссияләре һәм эшче төркемнәре карарлары бәяләмәләр, тәкъдимнәр һәм мөрәҗәгатьләр рәвешендә кабул ителә торган тәкъдим итү төсмеренә ия.

2. Иҗтимагый палата карарлары Иҗтимагый палата әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3. Иҗтимагый палатаның Иҗтимагый палата Регламентын раслау турындагы, аңа үзгәрешләр кертү турындагы, Иҗтимагый палатаның үз-үзен таратуы турындагы, әлеге Законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән нигез буенча һәм Иҗтимагый палата Регламентында каралган башка очракларда, Иҗтимагый палата әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карарлар Иҗтимагый палата әгъзаларының билгеләнгән саныннан өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.

4. Иҗтимагый палата карарлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның шушы карарлар җибәрелгән вазыйфаи затлары тарафыннан һичшиксез каралырга тиеш. Карарларны карау нәтиҗәләре турында Иҗтимагый палатага язма рәвештә хәбәр ителә.

5. Иҗтимагый палатаның кабул ителгән карары белән килешмәгән Иҗтимагый палата әгъзалары үзләренең үзгә фикерләрен язма рәвештә бәян итәргә мөмкин. Иҗтимагый палата әгъзаларының кимендә өчтән бере тарафыннан имзаланган үзгә фикер Иҗтимагый палата карарына кушымта итеп өстәлә һәм аның белән бергә җибәрелә.

22 статья. **Иҗтимагый палатаның дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлеге**

Иҗтимагый палатаның дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлеге түбәндәгечә тәэмин ителә:

1) тиешле дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары Иҗтимагый палатаның алар адресына җибәрелгән карарларын һичшиксез карап һәм алар буенча органның дәлилләнгән карарларын чыгарып;

2) Иҗтимагый палата советы тарафыннан рәсми вәкаләтләр тапшырылган Иҗтимагый палата әгъзалары Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан үткәрелә торган киңәшмәләр эшендә, Дәүләт Советы, Дәүләт Советы комитетлары, Министрлар Кабинеты утырышлары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының коллегияләре эшендә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары уздыра торган башка чараларда киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашып;

3) Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең мөһим мәсьәләләре буенча уртак җәмәгать тыңлаулары, конференцияләр һәм фикер алышуның башка рәвешләрен уздырып.

23 статья. **Иҗтимагый палатаның җәмәгать күзәтчелеге комиссиясе белән үзара эшчәнлеге**

Иҗтимагый палата мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасында федераль законнар нигезендә төзелгән җәмәгать күзәтчелеге комиссиясе белән үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыра.

24 статья. **Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре**

1. Иҗтимагый палатага Федераль закон һәм әлеге Закон белән йөкләнгән бурычларны үтәүне максатларында Иҗтимагый палата түбәндәгеләргә хокуклы:

1) “Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында” 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә аерым гавами вәкаләтләр башкаручы бүтән оешмалар эшчәнлегенә җәмәгать контролен үткәрергә;

2) Иҗтимагый палата Регламентында билгеләнгән тәртиптә җәмгыять өчен мөһим проблемалар буенча гражданнар катнашында форумнар, тыңлаулар, “түгәрәк өстәл”ләр һәм башка чаралар уздырырга;

3) Иҗтимагый палата утырышларына Татарстан Республикасы Президенты вәкилләрен, Дәүләт Советы депутатларын, Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкилләрен, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм башка затларны чакырырга;

4) Иҗтимагый палата советы тарафыннан вәкаләтләр бирелгән Иҗтимагый палата әгъзаларын Иҗтимагый палата Регламенты нигезендә Дәүләт Советы комитетлары (комиссияләре) эшендә, Министрлар Кабинеты утырышларында, башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары коллегияләрендә катнашу өчен җибәрергә;

5) Иҗтимагый палата гарызнамәләрен җибәрергә. Иҗтимагый палата утырышлары арасындагы чорда Иҗтимагый палата исеменнән гарызнамәләр Иҗтимагый палата советы карары буенча җибәрелә;

6) Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы башкарма хакимият

органнарының норматив хокукый актлары проектларына, җирле үзидарә органнарының хокукый актлары проектларына экспертиза ясарга;

7) дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан законнар бозылу турында бәяләмәләр бирергә һәм күрсәтелгән бәяләмәләрне компетентлы дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яки вазыйфаи затларга юлларга;

8) иҗтимагый тормышның төрле мәсьәләләре буенча инициативалар белән чыгарга, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кертергә;

9) үз эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша республика халкына мәгълүмат биреп торырга;

10) эшчәнлекләре Татарстан Республикасында граждан җәмгыятен үстерүгә юнәлдерелгән коммерциягә карамаган оешмаларга методик материаллар белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә;

11) Иҗтимагый палата Регламенты нигезендә экспертлар җәлеп итәргә.

2. Иҗтимагый палата шулай ук федераль законнарда, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән башка хокукларга ия.

25 статья. **Иҗтимагый палатага мәгълүмат бирү**

1. Иҗтимагый палата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт оешмаларына һәм муниципаль оешмаларга, федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына бу органнар һәм оешмалар компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча гарызнамәләр җибәрергә хокуклы. Иҗтимагый палата гарызнамәләре аның әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән максатларына һәм бурычларына туры килергә тиеш.

2. Иҗтимагый палата гарызнамәләре җибәрелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тиешле гарызнамә теркәлгән көннән алып утыз көн эчендә Иҗтимагый палатага аны карау нәтиҗәләре турында мәгълүмат җиткерергә, шулай ук аңа үз вәкаләтләрен үтәү өчен кирәкле белешмәләрне, шул исәптән документларны һәм материалларны тапшырырга тиеш, моңа дәүләт серен һәм федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләр керми. Аерым очракларда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы яисә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органы җитәкчесе, җирле үзидарә органы җитәкчесе йә шуңа вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат күрсәтелгән гарызнамәне карау срогын, Иҗтимагый палатага хәбәр итеп, иң күбе утыз көнгә озайтырга хокуклы.

3. Иҗтимагый палата гарызнамәсенә җавап бу гарызнамә юлланган вазыйфаи зат йә аның вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан имзаланган булырга тиеш.

26 статья. **Иҗтимагый палата әгъзаларының Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы һәм муниципаль берәмлекләрдәге иҗтимагый советлар эшендә катнашуы**

1. Иҗтимагый палата советы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы һәм җирле үзидарә органы җитәкчеләренә иҗтимагый совет төзү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы иҗтимагый советларны төзү тәртибе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, ә муниципаль берәмлекләрдә уставлар һәм (яисә) башка муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

3. Иҗтимагый палата әгъзалары иҗтимагый советлар эшендә катнаша ала.

27 статья. **Иҗтимагый палатаның Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турындагы еллык докладı**

1. Календарь ел беткәннән соң Иҗтимагый палата Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында еллык доклад әзерли һәм аны рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгара, шулай ук Иҗтимагый палатаның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыра.

2. Иҗтимагый палатаның еллык докладı Татарстан Республикасы Президентына, Дәүләт Советына, Министрлар Кабинетына җибәрелә, шулай ук Иҗтимагый палата карары буенча башка дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына җибәрелергә мөмкин.

3. Иҗтимагый палата рәисе еллык доклад белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында чыгыш ясый.

28 статья. **Иҗтимагый экспертиза**

1. Иҗтимагый палата Иҗтимагый палата советының карары белән йә Татарстан Республикасы Президенты, Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына, җирле үзидарә органнарының хокукый актлары проектларына экспертиза уздырырга хокуклы.

2. Экспертиза уздыру өчен Иҗтимагый палата эшче төркем төзи, ул түбәндәгеләргә хокуклы:

1) экспертлар җәлеп итәргә;

2) Иҗтимагый палатага экспертиза уздыру өчен кирәкле документлар һәм материаллар сорап Дәүләт Советына, Министрлар Кабинетына, Татарстан

Республикасы башкарма хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына гарызнамә җибәрүне тәкъдим итәргә;

3) Иҗтимагый палатага экспертиза ясалырга тиешле закон проектларын караганда Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре эшендә катнашу өчен Иҗтимагый палата әгъзаларын җибәрүне тәкъдим итәргә;

4) Иҗтимагый палатага экспертиза ясалырга тиешле норматив хокукый актлар проектларын караганда Министрлар Кабинеты утырышларына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары коллегияләренә Иҗтимагый палата әгъзаларын җибәрүне тәкъдим итәргә.

3. Иҗтимагый палата утырышлары арасында аның әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләрен Иҗтимагый палата советы гамәлгә ашыра.

4. Татарстан Республикасы законнары проектлары Иҗтимагый палатага Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрелә. Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган Гавами өстенлекләр реестрына кертелгән чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән норматив хокукый актлар проектлары, экспертиза үткәрү өчен кирәкле документлар һәм материаллар белән бергә, Иҗтимагый палатага Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан җибәрелә. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының башка норматив хокукый актлары проектлары Иҗтимагый палатага Иҗтимагый палата гарызнамәсе буенча җибәрелә.

### 29 статья. **Иҗтимагый экспертиза нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый палата бәяләмәсе**

1. Татарстан Республикасы законнары проектларына, Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына һәм җирле үзидарә органнарының хокукый актлары проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый палата бәяләмәләре тәкъдим итү характерында була һәм Татарстан Республикасы Президентына, Дәүләт Советына, Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

2. Татарстан Республикасы законнары проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый палата бәяләмәсе Дәүләт Советы утырышларында мәҗбүри каралырга тиеш.

3. Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый палата бәяләмәләре тиешенчә Министрлар Кабинеты утырышларында һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының коллегияләрендә һичшиксез каралырга тиеш.

4. Тиешле норматив хокукый актлар проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый палата бәяләмәләрен караганда Дәүләт Советы утырышларына,

шулай ук Министрлар Кабинеты утырышларына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары коллегияләренә Иҗтимагый палата советы тарафыннан вәкаләт бирелгән Иҗтимагый палата әгъзалары чакырыла.

5. Җирле үзидарә органнарының хокукый актлары проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый палата бәяләмәләре җирле үзидарәнең тиешле органнары тарафыннан һичшиксез каралырга тиеш.

5 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

30 статья. **Иҗтимагый палата әгъзасының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру шартлары**

1. Иҗтимагый палата әгъзасы үз вәкаләтләрен, әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, эштән азат ителмәгән килеш түләүсез нигездә гамәлгә ашыра.

2. Иҗтимагый палата әгъзасы үзенең Иҗтимагый палата әгъзасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле үз акчалары исәбеннән тотылган чыгымнар өчен Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм күләмнәрдә компенсация алырга хокуклы.

3. Иҗтимагый палата рәисе, Иҗтимагый палата рәисе урынбасарлары үз вәкаләтләрен, кагыйдә буларак, эштән азат ителмәгән нигездә гамәлгә ашыралар. Аерым очракларда Иҗтимагый палата карары буенча Иҗтимагый палата рәисе, шулай ук Иҗтимагый палата рәисе урынбасарларының берсе даими нигездә эшләргә мөмкин.

4. Даими нигездә эшләүче Иҗтимагый палата рәисенең, Иҗтимагый палата рәисе урынбасарының вазыйфаи окладлы күләме, хезмәт өчен түләүнең һәм эшчәнлекне матди-техник тәэмин итүнең башка шартлары Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

31 статья. **Иҗтимагый палата эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү**

1. Иҗтимагый палата эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү һәм Иҗтимагый палата карый торган мәсьәләләрдән, шулай ук Иҗтимагый палата эше нәтиҗәләреннән халыкның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өчен Иҗтимагый палата аппараты тарафыннан “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Иҗтимагый палатаның сайты төзелә һәм даими тулыландырып торыла.

2. Иҗтимагый палата үз эшчәнлеге турында халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша даими мәгълүмат биреп тора.

32 статья. **Иҗтимагый палата аппараты**

1. Иҗтимагый палата эшчәнлеген оештыру ягыннан, хокукый, аналитик, мәгълүмати, документлар белән тәэмин итү, финанс белән һәм матди-техник тәэмин итү Иҗтимагый палата аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Иҗтимагый палата аппараты дәүләт учреждениесе булып тора, аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән һәм үз исеме язылган мөһере була.

3. Иҗтимагый палата аппараты җитәкчесе үз вазыйфасына Иҗтимагый палата советы тәкъдиме белән Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнеп куела һәм азат ителә.

4. Иҗтимагый палата аппараты структурасы һәм хезмәткәрләренең иң чик саны Иҗтимагый палата рәисе тәкъдиме белән Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

33 статья. **Иҗтимагый палата эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү**

1. Иҗтимагый палата эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсе булып тора.

2. Иҗтимагый палата аппаратын тотуны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

34 статья. **Татарстан Республикасы аерым законнарының үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәге Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш);

2) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2007 елның 30 октябрендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 10);

3) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2008 елның 26 ноябрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 11 (III өлеш);

4) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2009 елның 18 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 12 (I өлеш);

5) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2012 елның 14 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш);

6) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2013 елның 6 ноябрендәге

85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 11 (I өлеш);

7) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 9 октябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 10 (I өлеш);

8) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында” 2016 елның 9 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 3 (I өлеш).

Статья 35. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

1. Әлеге Закон, аның 34 статьясыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 34 статьясы шушы Закон үз көченә кергән көнгә эшли торган Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре туктатылган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның гамәли көче шушы Закон үз көченә кергән көннән соң төзелә башлаган Иҗтимагый палатаның төзелүенә һәм эшчәнлегенә бәйле рәвештә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2017 ел, 27 апрель
№ 24-ТРЗ